ГЛАВА УРУССИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с. Старые Уруссу, ул. Советская,
д.16в, 423960

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Иске Урыссу авылы, Совет урамы,
16в йорт, 423960

Тел.: (85593) 4-42-31, факс: 4-41-52, e-mail: Uruss.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
N 2 16 ноябрь 2022 ел

2023 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Ютазы муниципаль районының Урыссу авыл җирлегенең Байлар торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Урыссу авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 июлендәге 7 санлы карары белән кабул ителгән Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Уставының 14, 81 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу авыл җирлеге советының 2019 елның 28 октябрендәге 14 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында»гы нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1.2022 елның 26 ноябрендә 10.00 сәгатькә Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Байлар торак пункты, Тукай урамы, 41 йорт адресы буенча урнашкан Байлар мәдәният йорты бинасында 2023 елда Ютазы муниципаль районының Урыссу авыл җирлегенең Байлар торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Урыссу авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге формада белем алучы студентлар, I төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы инвалидларының тол хатыннары, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, 2023 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- Байлар торак пунктының Яңа тыкрыгы буенча юлны норматив хәлгә китерү (төзелеш, реконструкция, асфальтлау, ремонтлау, вак ташлау, төзелеш материаллары сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- зират коймасын урнаштыру (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләрне түләү);

- авыллар эчендәге юлларны карап тоту (грейдерлау, юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Урыссу авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга (http://yutaza.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә урнаштырырга

4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән (халыкка җиткерелгән) үз көченә керә.

Ютазы муниципаль районы
Урыссу авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Әминова